ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                КАРАР

31.12.2019          с. Верхний Услон          1343

Югары Ослан муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә 2020 елга укучыларның туклануын оештыру турында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, укучыларның балансланган кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542нче номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга айлык акчалата түләүләр һәм башка төр түләүләр турында» 2009 елның 28 августындагы 724нче номерлы карары нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә:
1.1 Югары Ослан муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын кайнар аш белән тәэмин итүне һәр уку көненә 7 сум 70 тиен һәм ата-ана түләвеннән торган суммага оештырырга.
1.2 27 сумлык кайнар иртәнге ашлар оештырырга, шул исәптән: 4 һәм аннан да күбрәк балалары һәм инвалид балалары булган гаиләләр өчен җирле бюджет акчалары хисабына 19 сум 30 тиен субсидия хисабына 7 сум 70 тиен.
1.3 туклануны оештыруны контрольдә тотырга
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Югары Ослан муниципаль районы бюджетында каралган ассигнованиеләр чикләрендә гомуми белем бирү учреждениеләренең барлык укучылары өчен уку вакытында кайнар туклануны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга.
3. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» Муниципаль казна учреждениесенә:

3.1 Витаминнар, микронутриентлар белән баетылган төп туклыклы матдәләрне карап тоту буенча балансланган иртәнге һәм төшке ашларның нормаларын һәм сыйфатын исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.
3.2 Укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән акчаларны максатчан куллануны һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә, мәктәп яны участоклары продукциясе хисабына мәктәп ашлары ассортиментын баету эшен көчәйтергә.
3.3 Гомуми белем бирү учреждениеләренә продуктларның өзлексез килүен координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.
4. Мәктәп укучыларын кайнар аш белән тәэмин итүче гомуми белем бирү учреждениеләре һәм башка предприятиеләр җитәкчеләренә:
4.1 Мәктәп ашханәләрен сыйфатлы азык-төлек белән өзлексез тәэмин итәргә.
4.2 Гомуми белем бирү учреждениеләрендә кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруны, санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар туклануын оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре» СанПин 2.4.5409-08 нормативлары нигезендә, «Санитар кагыйдәләрне үтәү һәм санитария-эпидемияләргә каршы (профилактика) чаралар үтәүгә производство контролен оештыру һәм үткәрү» СП 1.1.1058-01 номерлы СанПиН нигезендә башкарырга.
5. 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләрдәге балалар өчен бирелгән ташламалар турындагы мәгълүмат ЕГИССО Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә куллану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматларга туры китереп алынырга мөмкин.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе начальнигы Касыймов В. В. йөкләргә

Башкарма комитет җитәкчесе В. С. Тимиряев